ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2023 г. Казань № 835-9/нпс-2023

Капиталь төзелеш объектларын дәүләт техник исәбенә алу һәм техник инвентаризацияләү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Торак фондын техник инвентаризацияләүгә ставкалар билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә торак фондын дәүләт исәбенә алу турында» 1997 елның 13 октябрендәге 1301 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларын дәүләт техник исәбенә алу һәм техник инвентаризацияләү эшләрен башкаруга вакыт нормаларын раслау турында» 2002 елның 15 маендагы 79 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 27.12.2023 №65-пр беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә капиталь төзелеш объектларын дәүләт техник исәбенә алу һәм техник инвентаризацияләү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Торак фондын техник инвентаризацияләүгә ставкалар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән ставкалар әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Капиталь төзелеш объектларын дәүләт техник исәбенә алу һәм техник инвентаризацияләү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Торак фондын техник инвентаризацияләүгә ставкалар билгеләү турында» 18.12.2018 №8-2/соц;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Дәүләт техник исәбе һәм капиталь төзелеш объектларын техник инвентарьлаштыру өлкәсендәге норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла

торган Татарстан Республикасы торак фондын техник инвентарьлаштыруга ставкалар билгеләү турында» 2018 елның 18 декабрендәге 8-2/соц карарына үзгәрешләр кертү хакында» 04.03.2020 № 9-3/соц-2020.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.12.2023 № 835-9/нпс-2023
карарына кушымта

# Капиталь төзелеш объектларын дәүләт техник исәбенә алу һәм техник инвентаризацияләү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы торак фондын техник инвентаризацияләүгә ставкалар

## 1. Фатирларны техник инвентаризацияләү ставкалары

| т/с | Эшләрнең атамасы һәм характеристикасы | Үлч. бер. | **Объектның мәйданы (м$^2$)** | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **40 кадәр** | **40 тан 60 ка кадәр** | **60 тан 80 гә кадәр** | **80 дән 100 гә кадәр** | **100 дән 150 гә кадәр** | **150 дән 200 гә кадәр** | **200 дән 250 гә кадәр** | **250 дән 300 гә кадәр** |
| | | | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. |
| 1 | Мәйданы 100 кв.метрга кадәр булган бинаны, бүлмәләрне тикшерү | 100 м$^2$ | 225,7 | 225,7 | 225,7 | 225,7 | 225,7 | 225,7 | 225,7 | 225,7 |
| 2 | Мәйданы 100 кв.метрдан артык булган бинаны, бүлмәләрне тикшерү | өстәмә рәвештә һәр 100 м$^2$ | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 67,7 | 67,7 | 135,4 | 135,4 |
| 3 | Аерым бүлмәләрдәге үзгәрешләрне исәпкә алу | бина (бүлмә) | 149,5 | 299,1 | 299,1 | 448,6 | 448,6 | 598,2 | 747,7 | 747,7 |
| 4 | Тәрәзә яки ишек уемнарын томалауны, санитар-техник яки/һәм җылыту приборларын һәм җиһазларын сүтүне исәпкә алу | уем, прибор | 31,0 | 31,0 | 31,0 | 31,0 | 31,0 | 31,0 | 31,0 | 31,0 |
| 5 | Тәрәзә яки ишек уемнарын тишүне, санитар-техник яки/һәм җылыту приборларын һәм җиһазларын урнаштыруны исәпкә алу | уем, прибор | 48,2 | 48,2 | 48,2 | 48,2 | 48,2 | 48,2 | 48,2 | 48,2 |
| 6 | Техник документациядә биналарның (бүлмәләрнең, фатирларның) билгеләнеше һәм номерлары үзгәрүенең чагылдыру | бина (бүлмә, фатир) | 42,3 | 84,6 | 84,6 | 127,0 | 127,0 | 169,3 | 211,6 | 211,6 |
| 7 | 1: 200 масштабында төрле планлы ике-өч турыпочмактан торган биналарның катлы планнарын сызу | 10 м$^2$ | 168,7 | 210,9 | 295,3 | 379,6 | 527,3 | 738,2 | 949,1 | 1160,0 |
| 8 | Бинаның инвентаризация бәясен билгеләү | бина (бүлмә) | 444,4 | 444,4 | 444,4 | 444,4 | 444,4 | 444,4 | 444,4 | 444,4 |
| 9 | Техник паспорт, җыелма техник паспорт яки башка техник документ төзү | бит | 197,5 | 197,5 | 197,5 | 197,5 | 197,5 | 197,5 | 197,5 | 197,5 |
| 10 | Белешмә ясау өчен кирәкле документларны өйрәнү | документ | 233,3 | 233,3 | 233,3 | 233,3 | 233,3 | 233,3 | 233,3 | 233,3 |
| 11 | Инвентарь эшен рәсмиләштерү | эш | 174,9 | 174,9 | 174,9 | 174,9 | 174,9 | 174,9 | 174,9 | 174,9 |
| 12 | Смета төзү | 1 бит | 22,6 | 22,6 | 22,6 | 22,6 | 22,6 | 22,6 | 22,6 | 22,6 |
| 13 | Инвентарь эшенә үзгәрешләр кертү | хокук иясе | 403,6 | 403,6 | 403,6 | 403,6 | 403,6 | 403,6 | 403,6 | 403,6 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14 | Мәгълүмат базасына үзгәрешләр кертү | хокук иясе | 129,6 | 129,6 | 129,6 | 129,6 | 129,6 | 129,6 | 129,6 | 129,6 |
| 15 | Инвентарь эшенә документларны тегеп кую | эш | 59,3 | 59,3 | 59,3 | 59,3 | 59,3 | 59,3 | 59,3 | 59,3 |
| 16 | Арттыру аппаратлары ярдәмендә күчермәләр ясау | А-4 форматындагы 1 бит | 101,6 | 101,6 | 101,6 | 101,6 | 101,6 | 101,6 | 101,6 | 101,6 |
| 17 | Транспортта объектка кадәр хәрәкәт итү | км | 479,7 | 479,7 | 479,7 | 479,7 | 479,7 | 479,7 | 479,7 | 479,7 |
| **18** | **Җәмгысе** | - | 2 911,9 | 3 146,0 | 3 230,4 | 3 506,6 | 3 721,9 | 4 124,7 | 4 595,2 | 4 806,1 |

## 2. Шәхси торак йортларны техник инвентаризацияләү ставкалары

| т/с | Эшләрнең атамасы һәм характеристикасы | Үлч. бер. | **Объектның мәйданы ($м^2$)** | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **70 кадәр** | **70 тән 100 гә кадәр** | **100 дән 150 гә кадәр** | **150 дән 200 гә кадәр** | **200 дән 300 гә кадәр** | **300 дән 400 гә кадәр** | **400 дән 500 гә кадәр** | **500 дән 700 гә кадәр** |
| | | | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. | ӨХС белән эшләр ставкасы, сум. |
| 1 | План буенча ике-өч турыпочмактан торган корылмаларны беренчел инвентаризацияләү (эшләр комплексы) | 100 $м^2$ | 1885,0 | 1885,0 | 1885,0 | 1885,0 | 1885,0 | 2450,5 | 2450,5 | 2639,0 |
| 2 | Мәйданы 100 кв.метрга кадәр булган бинаны, бүлмәләрне тикшерү | бина, бүлмә | 228,0 | 228,0 | 228,0 | 228,0 | 228,0 | 228,0 | 228,0 | 228,0 |
| 3 | Мәйданы 100 кв.метрдан артык булган бинаны, бүлмәләрне тикшерү | өстәмә рәвештә һәр 100 $м^2$ | 0,0 | 0,0 | 34,2 | 68,4 | 136,8 | 205,2 | 273,6 | 410,4 |
| 4 | Эш корылмаларын һәм ишегалды корылмаларын тикшерү | данә | 51,3 | 51,3 | 102,6 | 51,3 | 102,6 | 102,6 | 102,6 | 102,6 |
| 5 | 1: 200 масштабында төрле планлы ике-өч турыпочмактан торган биналарның катлы планнарын сызу | 10 $м^2$ | 298,2 | 340,8 | 532,5 | 745,6 | 1171,6 | 1491,1 | 1917,1 | 2556,2 |
| 6 | Төзелешнең инвентаризация бәясен билгеләү | бина, янкорма | 1009,8 | 1009,8 | 1009,8 | 1009,8 | 1009,8 | 1009,8 | 1009,8 | 1009,8 |
| 7 | Төп корылмаларның инвентаризация бәясен ачыклау | бина, янкорма | 841,5 | 841,5 | 841,5 | 841,5 | 841,5 | 841,5 | 841,5 | 841,5 |
| 8 | Хезмәт корылмаларын инвентаризацияләү | 20 $м^2$ | 190,9 | 190,9 | 190,9 | 190,9 | 286,4 | 286,4 | 286,4 | 286,4 |
| 9 | Салкын янкормаларны инвентаризацияләү | 10 $м^2$ | 518,7 | 518,7 | 518,7 | 518,7 | 778,0 | 778,0 | 778,0 | 778,0 |
| 10 | Ишегалды корылмаларын инвентаризацияләү: капкалар, коелар, чүп җыю урыннары һ.б. | данә | 168,1 | 168,1 | 168,1 | 168,1 | 168,1 | 168,1 | 168,1 | 168,1 |
| 11 | Коймаларны инвентаризацияләү | 100 м | 216,6 | 216,6 | 216,6 | 216,6 | 259,9 | 216,6 | 324,9 | 324,9 |
| 12 | Хезмәт корылмаларының инвентаризация бәясен билгеләү | төзелеш корылмасы | 299,2 | 299,2 | 299,2 | 299,2 | 299,2 | 299,2 | 299,2 | 299,2 |
| 13 | Салкын янкормаларның инвентаризация бәясен билгеләү | янкорма | 164,6 | 164,6 | 329,1 | 329,1 | 329,1 | 329,1 | 329,1 | 493,7 |
| 14 | Ишегалды корылмаларының инвентаризация бәясен билгеләү | данә | 115,9 | 115,9 | 115,9 | 115,9 | 115,9 | 115,9 | 115,9 | 115,9 |
| 15 | Коймаларның инвентаризация бәясен билгеләү | койма төре | 138,4 | 138,4 | 138,4 | 138,4 | 138,4 | 138,4 | 138,4 | 138,4 |
| 16 | Тыныч рельефлы, төзелеш тыгызлыгы 20% кадәр булган җир кишәрлегендә инвентаризация эшләре. Яшеллекләр мәйданның 10% кадәр өлешен биләп тора, планда кишәрлек турыпочмаклы | 100 $м^2$ | 615,5 | 1025,9 | 1025,9 | 1025,9 | 1231,1 | 1231,1 | 1538,8 | 1538,8 |
| 17 | Техник паспорт, җыелма техник паспорт яки башка техник документ төзү | бит | 1097,1 | 1097,1 | 1097,1 | 1097,1 | 1097,1 | 1097,1 | 1097,1 | 1097,1 |
| 18 | Белешмә ясау өчен кирәкле документларны өйрәнү | документ | 235,6 | 235,6 | 235,6 | 235,6 | 235,6 | 235,6 | 235,6 | 235,6 |
| 19 | Инвентарь эшен рәсмиләштерү | эш | 176,7 | 176,7 | 176,7 | 176,7 | 176,7 | 176,7 | 176,7 | 176,7 |
| 20 | Смета төзү | эш | 22,8 | 22,8 | 22,8 | 22,8 | 22,8 | 22,8 | 22,8 | 22,8 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | Инвентарь эшенә үзгәрешләр кертү | хокук иясе | 407,7 | 407,7 | 407,7 | 407,7 | 407,7 | 407,7 | 407,7 | 407,7 |
| 22 | Мәгълүмат базасына үзгәрешләр кертү | хокук иясе | 130,9 | 130,9 | 130,9 | 130,9 | 130,9 | 130,9 | 130,9 | 130,9 |
| 23 | Инвентарь эшенә документларны тегеп кую | эш | 59,8 | 59,8 | 59,8 | 59,8 | 59,8 | 59,8 | 59,8 | 59,8 |
| 24 | Арттыру аппаратлары ярдәмендә күчермәләр ясау | А-4 форматындагы 1 бит | 188,1 | 188,1 | 188,1 | 188,1 | 188,1 | 188,1 | 188,1 | 188,1 |
| 25 | Транспортта объектка кадәр хәрәкәт итү | км | 775,1 | 775,1 | 775,1 | 775,1 | 775,1 | 775,1 | 775,1 | 775,1 |
| **26** | **Җәмгысе** | - | 9 835,6 | 10 288,6 | 10 730,4 | 10 926,3 | 12 075,3 | 12 985,4 | 13 895,8 | 15 024,7 |

Искәрмәләр:

1. Капиталь төзелеш объектларын дәүләт техник исәбенә алу һәм техник инвентарьлаштыру өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы торак фондының типлаштырылган төрләре буенча объектлар милекчеләре акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган техник инвентарьлаштыруга ставкалар (алга таба – Ставкалар) милек рәвешенә бәйсез рәвештә күчемсез мөлкәтне техник инвентаризацияләү һәм паспортлаштыру эшчәнлеген гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешмалар тарафыннан куллану өчен билгеләнгән.
2. Ставкалар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә һәм торак фондын (физик һәм юридик затлар заявкалары буенча фатирларны һәм шәхси торак йортларны) техник инвентаризацияләү буенча гамәлгә ашырыла торган эшләргә кагыла:

- торак урынны торак булмаган урынга яки торак булмаган урынны торак урынга күчерү;
- торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру.

3. Техник инвентаризация эшләрен башкару вакыты 10 эш көненнән артмый.

Гаризаларны ашыгыч рәвештә (4 эш көненнән дә артык түгел) үтәгәндә 1,5 коэффициенты кулланыла.

Ашыгыч заявканы үтәү клиент инициативасы буенча килешүдә ашыгычлыкны мөһим шарт буларак күрсәтеп рәсмиләштерелә.

4. Ставкалар кыр эшләрен үткәрү өчен уңайлы ел чорын һәм объектларда эшләрне үткәрүнең нормаль шартларын исәпкә алып билгеләнгән.

Эшләрне уңайсыз чорда үткәргәндә вакыт нормаларына кыр стадиясендә сезонлы арттыру коэффициентлары кулланыла. Татарстан Республикасында уңайсыз чорның дәвамлылыгы – 6 ай, 1 ноябрьдән 1 майга кадәр:

ноябрь, апрель – 1,18 коэффициенты;

декабрь, март – 1,25 коэффициенты;

гыйнвар, февраль – 1,43 коэффициенты.

Уңайсыз чорның уртача озынлыгы өчен сезон коэффициенты интерполяция белән билгеләнә.

5. Ставкалар сумнарда билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге